**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

өченче утырыш
**КАРАРЫ**

12 нче ноябрь 2025 ел **№ 10** Теләче авылы

Теләче муниципаль районы Советының 2014 елның 4 апрелендәге 199 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 03 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Теләче муниципаль районы Советының 2014 елның 4 апрелендәге 199 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган (26.05.2014 № 210, 15.11.2016 № 67, 20.04.2017 № 84, 19.07.2017 № 90, 12.04.2018 № 127, 24.08.2018 № 141, 13.12.2018 № 160, 20.01.2020 № 224, 30.07.2020 № 246, 03.09.2020 № 248, 30.06.2021 № 63, 01.02.2023 № 171, 20.10.2023 № 210, 28.12.2023 № 229, 07.03.2024 № 233, 02.07.2024 № 250, 28.08.2024 № 260, 25.12.2024 № 294) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба текст буенча - Нигезләмә) үзгәреш кертергә, түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1.1. «3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типлаштырылган квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарындагы вазыйфалардан тыш, вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәүче төркемнәре өчен; авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарында вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу:

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата:

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы кимендә бер ел яки белгечлек, юнәлеш буенча кимендә ике ел эш стажы.»;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы яисә кимендә бер ел әзерлек юнәлеше буенча эш стажы.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

Теләче муниципаль
районы башлыгы

А.Г. Фатхуллин